Авылларда почталарны модерни-зациялəv Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча алып барыла.
Лəмберə районы Пензятка авылынын почта элемтəсе бvлеге бинасына кvптəн капиталь ремонт кирəк булган. Хəзерге вакытта объектны капиталь ремонтлау ахырына якынлаша, алда тантаналы ачылу. Лəмберə региональ сайлау округы буенча Мордовия госсобрание депутаты Надия Харис кызы Заликова житəкчелегендə «Партия десанты» тозеклəндерелə торган бинаны карады һəм башкарылган эшлəрнен сыйфатын бəялəде.
Янарту кысаларында иске тəрəзəлəр яна ПВХларга алыштырылды, диварлар һəм тvшəмнəр буялды, санузел тозеклəндерелде, керv торкеменə ремонт ясалды, электр vткəргечлəр алыштырылды, монтаж эшлəре башкарылды. Мониторингта катнашучыларнын барысы да билгелəнгəн барлык нормаларга туры килгəн ремонтнын югары сыйфатын билгелəделəр.
Модернизациядəн сон Пензятка почта бvлеге халык очен тагын да кинрəк хезмəт кvрсəтə алачак. Бу районадагы кvп функцияле Үзəккə барырга кирəк тə булмас, бигрəк олкəн яшьтəге кешелəргə тормышны жинелəйтəчəк, ə кирəкле хезмəтне монда, урында, vз почта бvлекчəсендə алырга момкин булачак.